**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422735, Высокогорский район РТ,**
**с. Ямашурма, ул. Советская, 5**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**422735, ТРБиектау районы,**
**Ямаширмә авылы,Советская ур., 5**

**Тел./факс: +7(84365) 77-7-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 15 октября 2015 года № 8

Җирле референдум билгеләү турында
Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә
кертү мәсьәләсе буенча авыл җирлеге
гражданнарның үзара салым акчаларын куллану

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 11_ статьясы нигезендә, " Татарстан Республикасы, Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2015 елның 6 октябрендәге 5 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» карары, Ямаширмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 6 октябрендәге 2 номерлы «Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы» референдумын үткәрүне башлап җибәрү турында " гы карары нигезендә Карар итте:

1. 2015 елның 6 декабренә Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслрга:

"2015 елда Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 100 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Ямаширмә авылы урам утларын ремонтлау

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http:/ vysokaya-gora.tatarstan.ru к

Ямаширмә авыл җирлеге башлыгы Ф.К.Мухтаров